**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

01.08.2023 № 902-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Төбәк дәүләт экология тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга бирелә торган җаваплар тикшерүдә тотыла торган затның зарури таләпләрне үтәве яки үтәмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге) үрнәген раслау турында» 2022 елның 28 февралендәге 155-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын федераль законнарга туры китерү максатында, шулай ук Министрлыкта кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә,

Б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Төбәк дәүләт экология тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга бирелә торган җаваплар тикшерүдә тотыла торган затның зарури таләпләрне үтәве яки үтәмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге) үрнәген раслау турында» 2022 елның 28 февралендәге 155-п номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 26.07.2022 ел, № 630-п, 13.03.2023 ел, № 256-п боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «А.М.Шиһаповка» сүзләрен «И.И.Гобәйдуллинга» сүзләре белән алмаштырырга;

Әлеге боерык белән расланган төбәк дәүләт экология тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (аларга бирелә торган җаваплар тикшерүдә тотыла торган затның зарури таләпләрне үтәве яки үтәмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге) үрнәгендә:

14 пунктта:

4 юлның өченче графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 89-ФЗ номерлы федераль закон) $13^{1}$ статьясы, РФ Хөкүмәтенең «Кара һәм төсле металл ватыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләүнең кайбер мәсьәләләре турында, шулай

ук кара һәм төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү турында» 2022 елның 28 маендагы 980 номерлы карары;

«Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар» дигән икенче графаның №9 соравында «зыянлы (пычрата торган)» сүзләрен «пычрата торган» сүзләренә алмаштырырга;

«Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар» дигән икенче графаның №10 соравында «зыянлы (пычрата торган)» сүзләрен «пычрата торган» сүзләренә алмаштырырга, «зыянлы» сүзен төшереп калдырырга;

«Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар» дигән икенче графаның №11 соравын түбәндәге редакциядә бирергә:

«11. Газны чистарту җайланмаларын һәм атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруны контрольдә тоту чараларын эксплуатацияләү кагыйдәләре үтәләме?»;

«Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар» дигән икенче графаның №17 соравында «һәм агулы» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр вазыйфаларын башкаручы,
министрның беренче урынбасары И.И.Гобәйдуллин